КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 28 октябрь г.Казань № 1147

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 22 февраль, 110 нчы карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 22 февраль, 110 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 30 декабрь, 1063 нче; 2015 ел, 8 май, 333 нче; 2015 ел, 17 июнь, 444 нче; 2015 ел, 30 ноябрь, 906 нчы; 2016 ел, 30 март, 181 нче; 2016 ел, 25 май, 349 нчы; 2016 ел, 13 сентябрь, 640 нчы; 2016 ел, 21 сентябрь, 670 нче; 2016 ел, 28 ноябрь, 877 нче; 2017 ел, 25 гыйнвар, 29 нчы; 2017 ел, 28 апрель, 254 нче; 2017 ел, 26 июнь, 430 нчы; 2017 ел, 12 август, 568 нче; 2017 ел, 6 октябрь, 766 нчы; 2017 ел, 11 декабрь, 967 нче; 2018 ел, 27 март, 176 нчы; 2018 ел, 10 май, 343 нче; 2018 ел, 29 август, 735 нче; 2018 ел, 20 декабрь, 1198 нче; 2019 ел, 16 гыйнвар, 12 нче; 2019 ел, 13 февраль, 102 нче; 2019 ел, 6 июнь, 474 нче; 2019 ел, 31 октябрь, 974 нче; 2019 ел, 30 декабрь, 1246 нчы; 2020 ел, 24 июль, 618 нче; 2020 ел, 11 ноябрь, 1012 нче, 2020 ел, 3 декабрь, 1089 нчы; 2021 ел, 28 июнь, 512 нче, 2021 ел, 19 ноябрь, 1107 нче, 2022 ел, 15 июль, 680 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре | Программаның федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән бюджет ассигнованиеләре күләмнәре 612 733 912,79 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:<br>2014 ел – 30 831 624,92 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 3 276 380,3 мең сум);<br>2015 ел – 40 434 999,8 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 10 287 192,8 мең сум);<br>2016 ел – 42 370 549,4 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 12 319 020,9 мең сум);<br>2017 ел – 39 584 370,3 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 8 141 860,8 мең сум);<br>2018 ел – 65 440 908,71 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 15 892 374,91 мең сум);<br>2019 ел – 63 989 186,46 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 20 146 126,41 мең сум);<br>2020 ел – 63 755 690,2 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 24 080 444,2 мең сум);<br>2021 ел – 59 404 099,7 мең сум (шул исәптән капиталь кертемнәргә – 16 450 706,4 мең сум);<br>2022 ел - 70 165 138,6 мең сум (шул исәптән капиталь кертемнәргә - 17 309 646,6 мең сум);<br>2023 ел - 66 028 835,9 мең сум (шул исәптән капиталь кертемнәргә - 10 953 213,3 мең сум).<br>2024 ел – 70 728 508,8 мең сум (шул исәптән капиталь кертемнәргә – 9 416 217,8 мең сум);<br>2025 елга акчалар күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә»; |

Программаның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программаның федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән бюджет ассигнованиеләре күләмнәре 539 148 421,29 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:

2014 ел – 30 831 624,92 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 3 276 380,3 мең сум);

2015 ел – 40 434 999,8 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 10 287 192,8 мең сум);

2016 ел – 42 370 549,4 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 12 319 020,9 мең сум);

2017 ел – 39 584 370,3 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 8 141 860,8 мең сум);

2018 ел – 65 440 908,71 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 15 892 374,91 мең сум);

2019 ел – 63 989 186,46 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 20 146 126,41 мең сум);

2020 ел – 63 755 690,2 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 24 080 444,2 мең сум);

2021 ел – 59 404 099,7 мең сум (шул исәптән капиталь кертемнәргә – 16 450 706,4 мең сум);

2022 ел - 70 165 138,6 мең сум (шул исәптән капиталь кертемнәргә - 17 309 646,6 мең сум);

2023 ел - 66 028 835,9 мең сум (шул исәптән капиталь кертемнәргә - 10 953 213,3 мең сум).

2024 ел – 70 728 508,8 мең сум (шул исәптән капиталь кертемнәргә – 9 416 217,8 мең сум);

2025 елга акчалар күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»;

Программаның 2 нче кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» ярдәмче программасында (алга таба – ярдәмче программа):

ярдәмче программа паспортында:

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | Ярдәмче программа чараларын федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау күләмнәре 148 273 184,42 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:<br>2014 ел – 3 276 380,3 мең сум;<br>2015 ел – 10 287 192,8 мең сум;<br>2016 ел – 12 319 020,9 мең сум;<br>2017 ел – 8 141 860,8 мең сум;<br>2018 ел – 15 892 374,91 мең сум;<br>2019 ел – 20 146 126,41 мең сум;<br>2020 ел – 24 080 444,2 мең сум;<br>2021 ел - 16 450 706,4 мең сум;<br>2022 ел - 17 309 646,6 мең сум;<br>2023 ел - 10 953 213,3 мең сум;<br>2024 ел - 9 416 217,8 мең сум. |

| | |
|---|---|
| | 2025 елга акчалар күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә»; |

«Ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (Ярдәмче программа нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары)» юлына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«һөнәри белем бирү оешмаларының тулай торакка мохтаҗ укучыларының гомуми санында тулай торак белән тәэмин ителгән һөнәри белем бирү оешмаларында укучыларның чагыштырма авырлыгын 90 процентка кадәр арттырырга;

югары белем бирү мәгариф оешмаларының тулай торакка мохтаҗ укучыларының гомуми санында тулай торак белән тәэмин ителгән югары белем бирү мәгариф оешмаларында укучыларның чагыштырма авырлыгын 70,2 процентка кадәр арттырырга»;

ярдәмче программаның 2 бүлегенең 7 бүлекчәсен яңа редакциядә бәян итәргә:

«7. Һөнәри белем бирү объектларының матди-техник базасын гамәлдәге объектларны реконструкцияләү һәм яңа объектлар төзү һәм лаборатория базасын яңарту исәбенә ныгыту, һөнәри белем бирү оешмаларына һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларына капиталь ремонт ясауны да кертеп (шул исәптән «Иннополис университеты торак комплексының 5 нче һәм 6-1 нче, 6-2 нче торак корпуслары» объектын төзү чараларын гамәлгә ашыру, түбәндәге адрес буенча: Иннополис шәһ., Университет ур., 1 й.»)

Һөнәри белем бирүнең яңа сыйфатына ирешү, аның абруен күтәрү һөнәри белем бирү оешмаларының һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларының матди-техник базасын ныгытудан, гамәлдәге уку биналарын һәм тулай торакларны реконструкцияләүдән, яңа объектлар төзүдән башка мөмкин түгел. Шул ук вакытта яңа төзелеш һәм капиталь ремонт - модернизациянең җитди финанс кертемнәре таләп итә торган иң ресурс юнәлешләре.

Яңа уку йортларын һәм тулай торакларны капиталь ремонтлау һәм төзү турындагы карарлар индивидуаль характерга ия һәм, барыннан да элек, ресурс үзәкләрен төзү буенча проектлар белән бәйле, шулай ук Татарстан Республикасының социаль һәм мәдәни үсеше өчен өстенлекле әһәмияткә ия һөнәри белем бирү оешмалары ярдәменә бәйле.

Лаборатор базасын яңарту базаларында ресурс үзәкләре һәм гамәли квалификацияләрнең күпфункцияле үзәкләре төзелә торган оешмаларда өстенлекле тәртиптә гамәлгә ашырыла. Шул ук вакытта яңа ачылган һөнәри белем бирү программалары буенча урта һөнәри белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләре нигезендә лаборатория базасын яңарту каралган, шулай ук проектны уртактан финанслау, профильле предприятие тарафыннан лаборатория базасын модернизацияләү кызыксыну уяткан очракта.

Чара кысаларында һөнәри белем бирү оешмаларының бюджеттан тыш эшчәнлеген үстерү чаралары һәм бюджеттан тыш эшчәнлектән алынган акчаларны биналарны капиталь ремонтлауга һәм яңа уку җиһазларын сатып алуга

юнәлдереләчәк.

2014 - 2021 еллар чорында Программа кысаларында һөнәри белем бирү оешмаларының 91 объекты ремонтланган.

«Фән һәм университетлар» илкүләм проектының «Фәнни тикшеренүләр һәм кадрлар әзерләү өчен инфраструктура үсеше» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасында 2022 – 2023 елларда Иннополис шәһ., Университет ур., 1 й. адресы буенча «Иннополис университеты торак комплексының 5 нче һәм 6-1 нче, 6-2 нче торак корпуслары» объектын төзү каралган.

2015 - 2017 елларда һөнәри белем бирү оешмаларын капиталь төзүне, реконструкцияләүне һәм капиталь ремонтлауны күздә тоткан чаралар исемлеге әлеге Ярдәмче программага 7 нче кушымтада бирелгән.

2018 - 2021 елларда һөнәри белем бирү оешмаларына һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларына капиталь төзүне, реконструкцияләүне һәм капиталь ремонтлауны күздә тоткан чаралар исемлеге әлеге Ярдәмче программага 12 нче кушымтада бирелгән.»;

ярдәмче программаның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Ярдәмче программа чараларын федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау күләмнәре 148 273 184,42 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:

2014 ел – 3 276 380,3 мең сум;
2015 ел – 10 287 192,8 мең сум;
2016 ел – 12 319 020,9 мең сум;
2017 ел – 8 141 860,8 мең сум;
2018 ел – 15 892 374,91 мең сум;
2019 ел – 20 146 126,41 мең сум;
2020 ел – 24 080 444,2 мең сум;
2021 ел - 16 450 706,4 мең сум;
2022 ел - 17 309 646,6 мең сум;
2023 ел - 10 953 213,3 мең сум;
2024 ел - 9 416 217,8 мең сум.

2025 елга акчалар күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»;

ярдәмче программаның 5 бүлегендәге таблицада:

16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «16. | Тулай торакка мохтаҗларның гомуми санында тулай торак белән тәэмин ителгән укучыларның чагыштырма авырлыгы, процентл | 50 | 60 | 70 | 80 | 85 | 90 | 90 | 90 | 90 | - | - | -»; |

түбәндәге эчтәлекле 51 - 52 пунктлар өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «51. | «һөнәри белем бирү оешмаларының тулай торакка мохтаҗ укучыларының гомуми санында тулай торак белән тәэмин ителгән һөнәри белем бирү оешмаларында укучыларның чагыштырма авырлыгы, процент | - | - | - | - | - | - | - | - | - | 90 | 90 | 90 |
| 52. | Югары белем бирү мәгариф оешмаларының тулай торакка мохтаҗ укучыларының гомуми санында тулай торак белән тәэмин ителгән югары белем бирү мәгариф оешмаларында укучыларның чагыштырма авырлыгы, процент | - | - | - | - | - | - | - | - | - | 64,9 | 64,9 | 70,2»; |

ярдәмче программага 1, 12 нче кушымталарны яңа редакциядә (карарга теркәләләр) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин